Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге
Шихазда торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

10 ноябрь, 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең Шихазда торак пунктында 2020 елның 10 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 270 (ике йөз җитмеш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 138 (бер йөз утыз сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 84 (сиксән дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 54 (илле дүрт).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

«Сез, 2021 елда Шихазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, Чернобыль АЭСын бетерү катнашучылары, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне, бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- зиратка юлны ремонтлау
- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе П.В. Сиваев